КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 май г.Казань № 457

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карары белән расланган «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәнең 4 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 май, 454 нче; 2019 ел, 23 ноябрь, 1073 нче; 2021 ел, 12 февраль, 75 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәнең 4 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә (механизм карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.
2. Бу карар 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 май, 457 нче карары редакциясендә)

«Мәгариф оешмаларының белем алучылары арасында хокук бозуларны профилактикалауга өлеш керткән өчен» номинациясендә материалларны бәяләү критерийлары

| Т/с | Критерий исеме | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Мәгариф оешмасының белем алучылары арасында җинаятьчелекнең һәм хокук бозуларның торышы (бәяләү критерие – белем алучылар ягыннан хокук бозуларны булдырмау, әгәр белем алучыларның берсе дә хокук бозмаган булса, баллар максималь санда куела) | + 10 |
| 2. | Белем алучылар тарафыннан түбәндәгеләр кылыну: | |
| 2.1. | җинаятьләр | – 5<br>(белем алучылар тарафыннан һәр кылынган җинаять өчен) |
| 2.2. | административ хокук бозулар | – 1<br>(белем алучылар тарафыннан һәр кылынган административ хокук бозу өчен) |
| 3. | Эчке эшләр органнарына түбәндәгеләрдә булышлык күрсәтү: | |
| 3.1. | балигъ булмаганнар тарафыннан һәм аларга карата кылынган җинаятьләрне ачуда | + 5<br>(мәгариф оешмасы администрациясе һәм (яки) педагогик хезмәткәрләр ярдәмендә эчке эшләр органнары хезмәткәрләре тарафыннан ачыкланган һәр җинаять өчен) |
| 3.2. | мәгариф оешмаларының вазыйфаи затларыннан җинаятьләр, хокук бозулар һәм девиант тәртипкә ия балигъ булмаганнар турында мәгълүмат алуда | + 5<br>(һәр алынган мәгълүмат өчен) |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 4. | Хокук бозуларны профилактикалау отрядларының яки хокук саклау юнәлешендәге башка иҗтимагый берләшмәләрнең мәгариф оешмаларында түбәндәгеләрне пропагандалауга юнәлдерелгән чараларны үткәрү эшчәнлеге: | + 1 (һәр үткәрелгән чара өчен) |
| 4.1. | хокукый белемнәрне (лекцияләр нигезендә пропаганда, брифинглар, түгәрәк өстәлләр, конкурслар, викториналар һ.б. үткәрү) | + 2 |
| 4.2. | сәламәт яшәү рәвешен (спорт ярышлары, викториналар һәм конкурслар һ.б. үткәрү) | + 2 |
| 5. | Белем алучылар гомуми белем бирү оешмаларында мәктәп эчендәге исәпкә куелды һәм һөнәри белем бирү оешмаларында эчке исәпкә куелды | + 1 (һәр исәпкә куелган кеше өчен) |
| 6. | Ял итүнең оештырылган формаларына җәлеп ителде | + 1 (ял итүнең оештырылган формаларына һәр җәлеп ителгән кеше өчен) |
| 7. | Хокук бозуларны профилактикалау субъектлары белән үзара хезмәттәшлек итү | + 2 (балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалауга юнәлдерелгән һәр үткәрелгән уртак чара өчен) |

______________________________